**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«28» 12 2022 ел Яр Чаллы шәһәре № 4209

«2022 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплексны программаны раслау турында» 2022 елның 16 мартындагы 779 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Тукай муниципаль районы территориясенең тиешле санитар, эстетик торышын тәэмин итү һәм аны алга таба төзекләндерү максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплексны программаны раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы 779 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Төп юнәлешләр һәм чаралар» 3 пунктын программа нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

2. 1 кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

# 2022 ЕЛГА ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЭКОЛОГИК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА КОМПЛЕКСЛЫ ПРОГРАММА

Яр Чаллы шәһәре
2022 ел

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td>Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплекслы программа</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td>Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td>- Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- авыл җирлекләре башкарма комитетлары;<br>- авыл җирлекләре башлыклары;<br>- коммуналь комплекс оешмалары</td></tr>
<tr><td>Программаның максатлары һәм бурычлары</td><td>Программаның төп максатлары:<br>- районның тотрыклы социаль-икътисадый үсешен су ресурслары белән гарантияле тәэмин итү;<br>- халыкның экологик уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүче су объектларын саклау һәм торгызу;<br>- халыкны һәм икътисад объектларын су басудан һәм суларның башка тискәре йогынтысыннан саклауны тәэмин итү;<br>- халыкның экологик уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүче су объектларын торгызу;<br>- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;<br>- Тукай муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру.<br>Бу максатларга ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү;<br>- су ресурсларының локаль дефицитларын бетерү;<br>- су объектларына тискәре антропоген йогынтыны киметү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру вакыты</td><td>2022</td></tr>
<tr><td>Финанслау күләме</td><td>Программаны финанслау күләме 7 085,0 мең сум тәшкил итә</td></tr>
<tr><td>Финанслау чыганаклары</td><td>Федераль бюджет, ТР бюджеты, район бюджеты, авыл җирлекләре, инвесторлар бюджетлары средстволары (мең сум)
<table>
<tr><td>Финан-слау чыга-нак-лары</td><td>ТР бюд-жеты</td><td>ТР бюд-жеты</td><td>Район бюджеты/ авыл җирлекләре бюджетлары средство-лары</td><td>Пред-приятие сред-ство-лары</td><td>Инвес-тиция-ләр</td></tr>
<tr><td>2022</td><td colspan="2">-</td><td>10 633,00</td><td></td><td></td></tr>
</table>
Эшләрнең бәясе, барлыгы 10 633,00 мең сум.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик зыянны булдырмый калу 7 085,0 мең сум күләмендә фаразлана.<br>Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру тиешле дәрәҗәдә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмау;<br>- район халкы өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру;<br>- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү;<br>- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирә мохиткә сак караш формалаштыру; экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру. |

## 1. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**Максатлар:**

- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;
- Тукай муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.

**Бурычлар:**

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә, тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән сәяси, икътисадый, технологик, хокукый, социаль, медицина, санитария-гигиена, эпидемиягә каршы чараларны исәпкә алып, дәүләт сәясәтен тормышка ашыру;

– җир, су, урман, минераль һәм башка ресурслардан файдалануның экологик нигезләнгән методларын кертеп, тотрыклы үсешкә юнәлтелгән табигатьтән комплекслы файдалануны гамәлгә кертү;

– хуҗалык эшчәнлегеннән тискәре экологик нәтиҗәләрне булдырмау, булачак экологик нәтиҗәләрне исәпкә алу;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итү системасының функциональ нәтиҗәлелеген тәэмин итү;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә карарлар әзерләүдә, фикер алышуда, кабул итүдә һәм тормышка ашыруда катнашуны тәэмин итү.

## 2. Тукай муниципаль районында экологик куркынычсызлыкны, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануны һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча эшчәнлекне анализлау

Халыкның көнкүреш һәм җитештерү эшчәнлегендә суны куллану һәм файдалану аны төрле элементлар белән баетуга китерә. Күргәнебезчә, кеше күпме су кулланса, шуның кадәре кире кайта. Табигый ки, аны табигатькә кайтарганчы, рөхсәт ителә торган чик концентрациянең тиешле нормаларына кадәр сыйфатлы итеп чистартырга кирәк.

Һәр торак пункт нәтиҗәле чистарту корылмаларына мохтаҗ. Әйләнә-тирә мохиткә нинди су әләгәчәге һәм моның киләчәктә экосистемада ничек чагылыш табачагы комплекслар эшенә бәйле. Әгәр сыек калдыклардан бөтенләй чистартылмый икән, үсемлекләр һәм хайваннар гына

үлми, туфрак агуланачак, ә зарарлы бактерияләр кеше организмына эләгеп, авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Агулы сыек калдыклары булган һәр предприятие чистарту корылмалары системасы белән шөгыльләнергә тиеш. Шулай итеп, бу табигать халәтендә чагылыш табачак һәм кешенең тормыш шартларын яхшыртачак. Әгәр чистарту комплекслары нәтиҗәле эшләсә, агынты сулар грунт һәм сулыкларга эләккәндә зыянсыз булачак. Чистарту корылмаларының зурлыгы һәм чистарту катлаулылыгы агынты суларның пычраклыгына һәм аларның күләменә нык бәйле.

Экология елдан-ел зур әһәмияткә ия. Икътисад һәм социаль өлкә динамик рәвештә үсә. Шуның белән бергә табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә дә йөкләнеш арта. Бу факторлар экологик проблемаларны җитди кискенләштерә. Әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү район халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшыртуда мөһим шарт булып тора. Халыкның тормыш эшчәнлеге калдыклары белән су объектларының пычрануы өслек суларының торышына тискәре йогынты ясый.

## 3. Төп юнәлешләр һәм чаралар.

**Локаль чистарту корылмалары**) – стационар канализация системасын үткәрү мөмкин булмаган урыннарда үзәк бәйсез шәһәр яны канализациясе функцияләрен башкару өчен билгеләнгән махсус җиһаз.

**Канализация челтәре** – түбәндәге бурычларны хәл итүче инженерлык системасы: авыл хуҗалыгы, сәнәгать производстволары һәм халык тормыш эшчәнлегенең сыек калдыкларны җыю һәм алга таба утильләштерү.

Һәр төзелә торган яңа объектны коммуникацияләргә тоташтыру зарур. Канализация системасының юынты суларын агызуны оештыру кирәклеге шактый сораулар тудыра.

Килеп туган шартларга карап, хуҗалык-көнкүреш агынтыларын утильләштерүнең нибары өч законлы варианты бар.

Алга таба чыгару өчен агынтыларны туплауның герметик системаларын оештыру (септиклар яки шакшы сулар чокыры). Бу иң гади юл, әмма эксплуатацияләүдә шактый кыйммәт.

Агынты суларны үзәкләштерелгән магистральгә бүлеп җибәрү. Әгәр мондый мөмкинлек булган очракта.

Автоном чистарту корылмаларын оештыру. Иң таралган вариант, бу юл уңайлылык, чыгымнар һәм эксплуатацияләү ягыннан караганда да оптималь.

Беренчел һәм бердәнбер дөрес юл булып, яңа, заманча, барлык экологик таләпләргә җавап бирә торган чистарту корылмаларына заказ бирү тора.

Хәзерге су бүлү системасы (су бүлү) дигәндә агызылган суларны җыелган урыннарында кабул итүне, биналардан читкә тиз агызуны, барлык торак урыннарыннан һәм сәнәгать предприятиеләреннән агызылган сулар җыюны, аларны чистарту корылмаларына җир асты торба үткәргечләре буенча тиз генә агызу, чистарту, зарарсызландыру һәм йогышландыру өчен аларны җир асты торба үткәргечләре буйлап агызуны тәэмин итүче санитар чаралар һәм катлаулы инженерлык корылмалары һәм җиһазлары комплексы аңлашыла.

Чистартылган һәм зарарсызландырылган агызылган сулар яисә нинди дә булса максатлар өчен (сәнәгатьне су белән тәэмин итү, авыл хуҗалыгында кырларны сугару өчен) кулланыла, яисә, мондый файдалану мөмкин булмаган яки икътисадый максатсызлык аркасында, су объектларына ташлана.

Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары – калдыкларны урнаштыру өчен каралмаган территорияләр. Калдыкларны шәһәр һәм авыл җирлекләре янындагы территорияләрдә, урман-парк, курорт, дәвалау-савыктыру, ял итү зоналарында, хайваннар миграциясе юлларында, уылдык чәчү урыннары янында һәм әйләнә-тирә мохит, табигый экологик системалар һәм кеше сәламәтлеге өчен куркыныч тудырырга мөмкин булган башка урыннарда урнаштыру тыела (мәсәлән, сусаклагычларның ярларында һәм вакытлыча су басу зоналарында, эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау территорияләрендә); шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән радиоактив калдыкларны, өске һәм җир асты су объектларына, су җыю мәйданнарына, җир асты һәм туфракка ташлау тыела. Моннан тыш, торак пунктлар, су саклау зоналары чикләрендә, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла торган җир асты су объектларының су җыю мәйданнарында калдыкларны күмү тыела

Җир кишәрлеге милекчесе каты коммуналь калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерүне мөстәкыйль тәэмин итәргә яки каты коммуналь калдыкларны региональ оператор белән рөхсәтсез ташлау өчен ачыкланган урынны бетерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзергә тиеш.

Яшелләндерү – үсемлек утыртмаларын булдыру һәм куллану белән бәйле эшләр җыелмасы; киңрәк мәгънәдә – әйләнә-тирә мохитнең экологик торышын яхшыртуга һәм территорияне төзекләндерүгә юнәлтелгән эшләр.

Яшелләндерү – шәһәрләрдә сәламәтләндерүнең төп чарасы һәм яшел киңлек булдыру, мөһим экологик әһәмияткә ия. Агачлар һәм куаклар оптималь микроклиматик шартлар тудыралар, һаваның газ составын көйлиләр, торак территорияләрне шәһәр тавышыннан саклыйлар, микроорганизмнарны юкка чыгаручы һәм үсешен тоткарлаучы фитонцидлар бүлеп чыгаралар, шулай ук эстетик матурлык чыганагы булып торалар.

## 4. Программаны финанс белән тәэмин итү.

2022 елга программаны тормышка ашыру өчен 10 633,00 мең сум акча кирәк.

## 5. Көтелгән соңгы нәтиҗәләр.

- әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмый калу;
- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.
- экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру;
- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирәлеккә сак караш формалаштыру;
- район халкы өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру.

1 кушымта

## 2022 елда Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына финанслауны күздә тоткан табигатьне саклау чаралары

| № | Чараның исеме | Үлчәү берәмлеге, егәрлек | Гамәлгә кертү вакыты | Агымдагы бәяләрдә бәясе, мең сумда | 01.01.2022 елга смета бәясенең калдыгы, мең сумда | 2022 елга лимит, мең сумда |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә һәм Олы Шилнә авыл җирлекләре өчен локаль чистарту корылмалары һәм канализация челтәрләре төзү буенча проект-смета документациясен эшләү | | 2022 | 6 586, 05374 | | 6 586, 05374 |
| 2 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Кувады авылы су бүлү системасын ремонтлау | | 2022 | 498, 94626 | | 498, 94626 |
| 3 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле торак пунктында калдыкларны рөхсәтсез ташлау урыннарын бетерү | | 2022 | 379,64 | | 379,64 |
| 4 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге Шөкрәле торак пунктында калдыкларны рөхсәтсез ташлау урыннарын бетерү | | 2022 | 379,64 | | 379,64 |
| 5 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә торак пунктында калдыкларны рөхсәтсез ташлау урыннарын бетерү | | 2022 | 599,95 | | 599,95 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә территорияне яшелләндерү | | 2022 | 724,53 | | 724,53 |
| 7 | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш торак пунктында калдыкларны рөхсәтсез ташлау урыннарын бетерү | | 2022 | 1 464,24 | | 1 464,24 |
| Барлыгы | | х | х | 10 633,00 | х | 10 633,00 |